**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№2** 09.12.2019 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Симәк авыл җирлеге составына керүче
Кызыл Яр торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенә керүче Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Кызыл Яр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә, көндезге формада укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларны, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Кызыл Яр авылының су коеларын демонтажлау;
- Кызыл Яр авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- Кызыл Яр авылы мәдәният оешмаларының ялын оештыру һәм анда яшәүчеләрне хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, Кызыл Яр авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Кызыл Яр авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру;
- Кызыл Яр авылы җирлеген төзекләндерүне оештыру;
- Кызыл Яр авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Кызыл Яр авылы суларын чыгаруны оештыру;
- Кызыл Яр авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;
- Кызыл Яр авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру »

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Кызыл Яр авылы, Наратлы урамы, 29а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Симәк авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Садертдинов